РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**14 апрель 2023 ел** **Чистай шәһәре** **№ 22/9**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Советының 2020 елның 22 июлендәге
56/6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2021 елның 21 деабарендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсе депутатына, сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибенә, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсе депутатына, сайланулы вазыйфаи затына карата карар кабул итү тәртибе турында» 2020 елның 22 июлендәге 56/6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук, әгәр әлеге белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында ялган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чараларына үзгәрешләр кертергә:

3 пунктның икенче абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның икенче абзацында, 6 пунктның беренче абзацында, 7 пунктның беренче һәм өченче абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)” сүзләре белән алыштырырга;

11 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» дигән сүзләрне «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» дигән сүзләр белән алыштырырга.

Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы Д.А. Иванов